Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Кече Шыңар торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында КАРАР

28.03.2024 № 2

06.10.2003 ел, № 131-ФЗ «Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында»гы Федераль законның 25.1, 56 статьяларына, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ЗРТ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясына, Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Уставының 23 нче маддәсенә, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге Советының 17.12.2021ел 29нчы номерлы "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шинар авыл җирлеге составына керүче торак пунктларда (торак пункт территориясенең бер өлеше) гражданнар җыенын әзерләү һәм үткәрү тәртибе турында Нигезләмәне раслау хакында карарына таянып, « Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Кече Шыңар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында» 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы "Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Кече Шыңар торак пунктында теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 2024 елда 773 сум күләмендә алынган акчалар конкрет чыгым юнәлешләренә юнәлтү: 1) Кече Шинар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау; 2) Кече Шыңар авылы зираты өчен бункер сатып алу; 3) Кече Шыңар авылында балалар мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу" турында карарында күрсәтелгән эш терләрен түбәндәге төрләргә үзгәртү өлешендә: 1) Кече Шыңар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау; 2) каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрнө бетерү (Кече Шыңар авылы зираты өчен бункер сатып алу); 3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Кече Шыңар авылында балалар мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу)" турында 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы карарына үзгәрешләр кертүгә ризамы мәсьәләсе буенча 2024 елның 28 мартында гражданнар җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә: Җыенда сайлау хокукына ия 257 кеше, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 130 кеше кертелгән. Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде: «Әйе» позициясе өчен гражданнар җыенында катнашучы 130 кеше тавыш бирде; «Юк» позициясе өчен җыенда катнашучы 0 кеше тавыш бирде. Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар итте:

1. Саба муниципаль районы составына керүче Олы Шыңар авыл җирлегенең Кече Шыңар авылында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.
2. "Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге составына керүче Кече Шыңар торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында 2023 елның 30 ноябрендәге 2 номерлы гражданнар җыены карарына, карарда күрсәтелгән эш төрләрен түбәндәге төрләргә үзгәртү өлешендә 1) Кече Шыңар авылы чикләрендә җирле әһәмияттәге автомобиль юлларын ремонтлау; 2) каты коммуналь калдыклар туплау мәйданчыкларын төзү, каты коммуналь калдыклар җыю өчен контейнерлар сатып алу, санкцияләнмәгән чүплекләрне бетерү (Кече Шыңар авылы зираты өчен бункер сатып алу); 3) торак пункт территориясен төзекләндерү (Кече

Шыңар авылында балалар мәйданчыгы өчен җиһазлар сатып алу) ; үзгәрешләр кертү турында” карарны кабул ителгән дип санарга.

3.Әлеге карарны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында түбәндәге адрес буенча: http://pravo.tatarstan.ru һәм Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлегенең рәсми сайтында түбәндәге адрес буенча: http://saby.tatarstan.ru/shinar һәм җирлекнең мәгълүмати стендларында бастырып чыгарырга.

4.Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Олы Шыңар авыл җирлеге башлыгы: А.Г.Гарипов